# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Шаршады торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

15.11.2021 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Шаршады торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 15 ноябрендә 14:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Шаршады торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

-Шаршады авылы Зәйнетдинов урамы өчен вак таш сатып алу һәм юл каплау;

-Шаршады авылының урамнарын кардан чистарту;

- халыкны су белән тәэмин итү (су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насосларын ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү, сатып алу);

-янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә хезмәт килешүе буенча түләү, янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

- урамнарны яктырту өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу, урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 180 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 109 кеше, бу 60 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 109 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Шаршады торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Шаршады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Шаршады торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

-приобретение и покрытие дороги щебнем по улице Зайнутдинова с.Шаршада;

-Шаршады авылы Зәйнетдинов урамы өчен вак таш сатып алу һәм юл каплау;

-Шаршады авылының урамнарын кардан чистарту;

- халыкны су белән тәэмин итү (су белән тәэмин итү өчен тирәнлек насосларын ремонтлау, аларга хезмәт күрсәтү, сатып алу);

-янгын сүндерү машинасы йөртүчесенә хезмәт килешүе буенча түләү, янгын сүндерү машинасы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу.

- урамнарны яктырту өчен яктылык диодлы лампалар сатып алу, урнаштыру.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы С.Л.Залетов